**УПРАВЛЕНИЕ ГОСУДАРСТВЕННЫХ ЗАКУПОК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ САТЫП АЛУЛАР ИДАРӘСЕ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.10.2013 № 09-16-151

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы дәүләт сатып алулары идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә гражданнар һәм дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

“Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында” Федераль законның 20 статьясы һәм Россия Федерациясе Президентының "Федераль дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләнгәндә гражданнар һәм федераль дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә федераль дәүләт хезмәткәрләре үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы вазыйфалар исемлеген раслау турында” 2009 елның 18 маендагы 557 номерлы Указы, “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына

билгеләнгәндә гражданнар һәм дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле вазыйфалары исемлеген раслау турында” 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы, “Коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт идарәсен камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2011 елның 21 ноябрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон һәм “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килү-килмәүгә күзәтчелек  хакында” 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон  нигезендә БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы дәүләт сатып алулары идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә гражданнар һәм дәүләт граждан вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле вазыйфалар исемлеген расларга.

2. Исемлеккә кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан җир кишәрлеген, башка күчемсез милек объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрен, акцияләрен (өлешле катнашу, оешмаларның устав (кушылу) капиталларындагы пайлар) сатып алу турындагы алыш-биреш килешүенә алыш-биреш килешүе төзелер алдыннан өч ел эчендә тотылган һәм алыш-биреш килешүе буенча үз чыгымнары, шулай ук хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының түләнгән акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр бирергә тиеш.

3. Исемлеккә кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан, әгәр әлеге оешма дәүләт идарәсенең аерым функцияләре дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи (хезмәттәге) таләпләренә кергән булса, таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча тиешле комиссия ризалыгы белән дәүләт граждан хезмәтеннән азат ителгәннән соң ике ел эчендә хезмәт шарнамәсе шартларында оешмада вазыйфа биләргә яисә әлеге оешмага бер ай дәвамында граждан-хокук шартнамәсе (граждан-хокук шартнамәләре) шартларында йөз мең сумнан артык күләмдәге эш башкарырга хокуклы.

4. Исемлеккә кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан дәүләт граждан хезмәтеннән азат ителгәннән соң ике ел эчендә эшләр башкару (хезмәтләр күрсәтү) турындагы граждан-хокук шартнамәсен имзалаганда эш бирүчегә үзенең соңгы хезмәт итү урыны турында хәбәр итәргә тиеш.

5. Исемлеккә кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданның дәүләт граждан хезмәтеннән азат ителгәннән соң әлеге Боекрыкның 3 пунктында каралган таләпне үтәмәве әлеге граждан белән төзелгән эшләр башкару (хезмәтләр күрсәтү) граждан-хокук шартнамәсен өзүгә китерә.

6. Структур бүлекчәләр җитәкчеләре әлеге Боекрыкның 1 пунктында каралган дәүләт граждан хезмәткәрләрен Исемлек белән таныштырырга тиеш.

7. Татарстан Республикасы дәүләт сатып алулары идарәсе җитәкчесенең 2012 елның 11 апрелендәге №06-15-68 Боерыгы үз көчен югалткан дип санарга.

8. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны җитәкче урынбасары Абдуллин Айдар Мансур улына йөкләргә.

Җитәкче О.А.Редько

Татарстан Республикасы дәүләт сатып алулары идарәсе җитәкчесе боерыгы белән расланган
2013 елның “04” 10
№09-16-151

**Татарстан Республикасы дәүләт сатып алулары идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына гражданнарны билгеләгәндә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфаларын үтәгәндә үз керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы вазыйфалар исемлеге**

| № | Вазыйфа |
|---|---|
| 1. | Җитәкче урынбасары |
| | |
| Үзәкләштерелгән сатып алулар бүлеге | |
| 1. | Бүлек башлыгы |
| 2. | Башлык урынбасары |
| 3. | Әйдәүче киңәшче |
| 4. | Әйдәүче консультант |
| 5. | 1нче разрядлы белгеч |
| | |
| Үзәкләштерелгән сатып алуларны анализлау һәм тәэмин итү бүлеге | |
| 1. | Бүлек башлыгы |
| 2. | Башлык урынбасары |
| 3. | Әйдәүче киңәшче |

| | |
|---|---|
| 4. | 1нче разрядлы өлкән белгеч |
| 5. | Әйдәүче белгеч - эксперт |
| 6. | 1нче разрядлы белгеч |
| | |
| Дәүләт контрактларын башкару бүлеге | |
| 1. | Бүлек башлыгы |
| 2. | Башлык урынбасары |
| 3. | Әйдәүче киңәшче |
| 4. | 1нче разрядлы өлкән белгеч |
| 5. | 1нче разрядлы белгече |
| | |
| Заказлар экспертизасы бүлеге | |
| 1. | Бүлек башлыгы |
| 2. | Башлык урынбасары |
| 3. | Әйдәүче киңәшче |
| | |
| 1. | Әйдәүче киңәшче |
| 2. | Әйдәүче белгеч |